| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» Сабакайка авыл торак пунктында 2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 27 октябреннән** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» Сабакайка авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Сабакайка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм сугыш инвалидлары, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына алынучы гражданнардан, 18 яшькә кадәр 3тән артык баласы булган гаиләләрдән тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту;
- балалар уен мәйданчыкларын сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
- һәйкәлләр төзү һәм төзекләндерү;
- зиратларны карап тоту һәм төзекләндерү
- су һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Сабакайка авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы «Алексеевск шәһәр**
**җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы** **С.А. Демидов**